**СОВЕТ СОКУРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422622 с.Сокуры,
ул. Школьная, д.1
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОКУРЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422622 Сокуры авылы,
Школьная урамы, 1 а нчы йорт,
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

**2026 елның «25» марты** **12 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы Нигезләмәне раслау турында**

2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Публик хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль закон, 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»гы Федераль закон нигезләмәләренә таянып, «Сокуры авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән, Сокуры авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы кушымта итеп бирелгән Нигезләмәне расларга.

2. Сокуры авыл җирлеге Советының 2023 елның 23 гыйнварындагы 02 номерлы «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы Нигезләмә хакында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (Интернет челтәрендәге адресы: http://pravo.tatarstan.ru) һәм Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында (Интернет челтәрендәге адресы: http://laishevo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз карамагымда калдырам.

5. Карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән башлап көченә керә.

**Сокуры авыл җирлеге Советы рәисе**
**– җирлек башлыгы:** **Р.Р. Мәүлиевв**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл**

**җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы**

**НИГЕЗЛӘМӘ**

**1 нче бүлек. Гомуми кагыйдәләр**

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль (алга таба – төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль) гамәлгә ашыру тәртибен билгели.

1.2. Төзекләндерү өлкәсендәге контрольнең предметы булып оешмалар һәм гражданнар (алга таба – контрольдә тотылучы затлар) тарафыннан Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге территориясендә Төзекләндерү кагыйдәләрен (алга таба – Төзекләндерү кагыйдәләре), инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларының, шулай ук күрсәтелә торган хезмәтләрнең үтемлелеген тәэмин итү таләпләрен (алга таба — мәҗбүри таләпләр) саклау тора.

1.3. Муниципаль контрольне Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге Башкарма комитеты (алга таба – Контроль органы) гамәлгә ашыра.

1.4. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру эшчәнлеге белән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе җитәкчелек итә.

1.5. Муниципаль контрольне турыдан-туры гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге (алга таба – инспекторлар) Контроль органының боерык акты белән билгеләнә.

1.6. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль гамәлгә ашыру, профилактик һәм контроль чараларын оештыру һәм үткәрү белән бәйле мөнәсәбәтләргә 31.07.2020 елгы 248-ФЗ номерлы Федераль закон, 20.03.2025 елгы 33-ФЗ номерлы «Публик хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль закон кагыйдәләре кулланыла.

1.7. Муниципаль контроль объектлары (алга таба – контроль объекты) булып түбәндәгеләр тора:

- контрольдә тотылучы затларның Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге территориясен төзекләндерү өлкәсендәге эшчәнлеге, хәрәкәтләре (хәрәкәтсезлеге), алар кысаларында мәҗбүри таләпләр сакланырга тиеш.

- контрольдә тотылучы затларның эшчәнлек нәтиҗәләре, шул исәптән мәҗбүри таләпләр куела торган эшләр һәм хезмәтләр;

- контрольдә тотылучы затлар биләгән һәм (яки) файдаланган биналар, корылмалар, объектлар, территорияләр (шул исәптән җир участоклары),

предметлар һәм төзекләндерү өлкәсендә мәҗбүри таләпләр куела торган башка объектлар.

1.8. Контроль органы төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында контроль объектларының исәбен алуны тәэмин итә.

**2 нче бүлек. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда канун белән саклanучы кыйммәтләргә зыян (зыян салу) китерү куркынычлары белән идарә итү**

2.1. Контроль органы төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне зыян (зыян салу) китерү куркынычлары белән идарә итү нигезендә гамәлгә ашыра.

2.2. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда канун белән саклanучы кыйммәтләргә зыян (зыян салу) китерү куркынычлары белән идарә итү максатыннан, әлеге Нигезләмәнең 1.7 пунктында күздә тотылган контроль объектлары 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә ярашлы рәвештә куркыныч категорияләренә кертелергә тиеш.

2.3. Контроль органы тарафыннан контроль объектларын билгеле бер куркыныч категориясенә кертү әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада китерелгән критерийлар нигезендә башкарыла. Контроль объектларын куркыныч категорияләренә кертү һәм аларны үзгәртү Башкарма комитетның боерыгы белән гамәлгә ашырыла.

Контроль объектларын куркыныч категорияләренә керткәндә түбәндәгеләр кулланыла:

1. Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрындагы мәгълүматлар;
2. контрольдә тотылучы затлар белән бәйләнешкә кермичә үткәрелгән чаралар барышында алынган мәгълүматлар;
3. Башкарма комитеттагы башка мәгълүматлар.

2.4. Контроль органы зыян китерү куркынычлары белән идарә итү максатыннан контроль объектларын түбәндәге куркыныч категорияләренең берсенә кертә:

1. уртача куркыныч (средний риск);
2. чамалы куркыныч (умеренный риск);
3. түбән куркыныч (низкий риск).

2.5. Гадәттән тыш югары һәм югары куркыныч категорияләренә кертелгән контроль объектлары булмау сәбәпле, планлы контроль чаралары үткәрелми.

2.6. Уртача һәм чамалы куркыныч категорияләренә кертелгән контроль объектлары өчен мәҗбүри профилактик визитларның ешлыгы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

31.07.2020 елгы 248-ФЗ номерлы Федераль законның 25 нче матдәсе 5 нче өлеше нигезендә, әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән контроль объектларына карата мәҗбүри профилактик визитлар үткәрелми.

«Әлеге пунктның нигезләмәләре 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 52.1 матдәсе 1 нче өлешенең 2–4 пунктларында һәм 2 нче өлешендә күрсәтелгән мәҗбүри профилактик визитларны үткәрүне чикләми».

## 3 нче бүлек. Канун белән сакланучы кыйммәтләргә зыян (зыян салу) китерү куркынычларын профилактикалау

3.1. 3.1. Контроль органы төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне, шул исәптән профилактика чаралары үткәрү аша да гамәлгә ашыра.

3.2. Профилактика чаралары контрольдә тотылучы затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне намуслы үтәүне стимуллаштыру, кагыйдә бозуга яки зыян китерүгә сәбәпче булган шартларны һәм факторларны бетерү, шулай ук әлеге таләпләрне һәм аларны үтәү ысулларын аңлату максатыннан үткәрелә.

3.3. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль гамәлгә ашырылганда, зыян китерү куркынычын киметүгә юнәлтелгән профилактика чаралары үткәрү контроль чараларына караганда өстенлекле булып тора.

3.4. Профилактика чаралары Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә расланган профилактика программасы нигезендә башкарыла. Шулай ук программада күздә тотылмаган профилактика чаралары да үткәрелергә мөмкин.

Әгәр профилактика чаралары барышында контроль объектларының канун белән сакланучы кыйммәтләргә ачыктан-ачык зыян китерү куркынычы янавы яисә зыян китерелүе ачыкланса, вазыйфаи зат бу хакта кичекмәстән Сокуры авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә хәбәр итә. Бу 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 нчы матдәсендә күрсәтелгән чараларны күрү өчен кирәк.

3.5. Контроль органы төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль кысаларында түбәндәге профилактика чараларын үткәрә ала:

1. мәгълүмат бирү (информирование);
2. хокук куллану практикасын гомумиләштерү;
3. кисәтү белдерү (объявление предостережения);
4. консультация бирү (консультирование).

5) профилактический визит.

3.6. Мәгълүмат бирү (информирование) Контроль органы тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча Сокуры авыл җирлегенең рәсми сайтындагы контроль эшчәнлегенә багышланган махсус бүлектә, массакүләм мәгълүмат чараларында, дәүләт мәгълүмат системаларындагы контрольдә тотылучы затларның шәхси кабинетлары аша (алар булган очракта) һәм башка формаларда гамәлгә ашырыла.

Сокуры авыл җирлеге Башкарма комитеты рәсми сайтның контроль эшчәнлегенә багышланган махсус бүлегендә 31.07.2020 елгы 248-ФЗ номерлы Федераль законның 46 нчы матдәсе 3 нче өлешендә күздә тотылган мәгълүматларны урнаштырырга һәм аларны актуаль халәттә тотарга бурычлы.

Контроль органы шулай ук муниципаль берәмлек халкын җыеннарда һәм конференцияләрдә контроль объектларына куела торган мәҗбүри таләпләр, аларның куркыныч категорияләренә туры килүе, шулай ук үткәрелә торган контроль чараларының төрләре һәм ешлыгы турында мәгълүмат бирергә хокуклы.

3.7. Хокук куллану практикасын гомумиләштерү Контроль органы тарафыннан үткәрелгән чаралар һәм аларның нәтиҗәләре турындагы мәгълүматларны җыю һәм анализлау аша башкарыла.

Хокук куллану практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләре буенча контрольгә вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан ел саен доклад әзерләнә. Бу доклад Сокуры авыл җирлеге Башкарма комитеты боерыгы белән раслана һәм хисап елыннан соң килүче елның 1 июленә кадәр рәсми сайтның махсус бүлегендә урнаштырыла.

3.8. Контроль органы контрольдә тотылучы затка мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү белдерә, әгәр мәҗбүри таләпләрне бозуга әзерлек яки бозу билгеләре турында мәгълүмат булса, шулай ук бу бозуның канун белән саклanучы кыйммәтләргә зыян китерүе яки зыян салу куркынычы тудыруы турында расланган мәгълүматлар булмаган очракта. Кисәтүдә мәҗбүри таләпләрне үтәүне тәэмин итү буенча чаралар күрергә тәкъдим ителә.

Кисәтү Россия Икътисади үсеш министрлыгының 31.03.2021 елгы 151 нче номерлы боерыгы белән расланган типик форма буенча рәсмиләштерелә.

Контрольдә тотылучы зат кисәтүне алган көннән башлап ун эш көне эчендә Контроль органына кисәтүгә карата каршылык (возражение) бирергә хокуклы. Каршылык дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы (Госуслуги) аша бирелергә мөмкин.

Каршылыкта түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш:

каршылык җибәрелә торган Контроль органының исеме;

юридик затның исеме, шәхси эшкуарның яки гражданинның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта), шулай ук элемтә өчен телефон номеры, электрон почта адресы һәм җавап җибәреләчәк почта адресы;

кисәтүнең датасы һәм номеры;

контрольдә тотылучы затның кисәтү белән риза булмавын раслаучы аргументлар (нигезләр);

кисәтүне алган дата;

шәхси имза һәм дата.

Контрольдә тотылучы зат үз аргументларын раслау өчен каршылыкка

тиешле документларны яки аларның расланган күчермәләрен теркәргә хокуклы. Контроль органы каршылыкны алган көннән башлап унбиш эш көне эчендә карый.

Каршылыкны карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

каршылыкны канәгатьләндерү һәм кисәтүне гамәлдән чыгару;

каршылыкны канәгатьләндерүдән баш тарту (сәбәбен күрсәтеп).

Контроль органы карар кабул ителгәннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча контрольдә тотылучы затка җавап җибәрә. Шул ук нигезләр буенча кабат каршылык бирү рөхсәт ителми. Контроль органы бирелгән кисәтүләрнең исәбен алып бара.

3.9. Консультация бирү (консультирование) вазыйфаи зат тарафыннан телефон аша, видеоконференция, «Инспектор» мобиль кушымтасы аша, шәхси кабул итү вакытында яки контроль чаралары барышында гамәлгә ашырыла.

Гражданнарны шәхси кабул итүне Башкарма комитет җитәкчесе яки башка вазыйфаи зат башкара. Кабул итү вакыты һәм урыны турындагы мәгълүмат рәсми сайтта урнаштырыла. Консультацияләр түбәндәге мәсьәләләр буенча телдән яки язмача бирелә:

төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне оештыру;

әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән контроль чараларын үткәрү тәртибе;

вазыйфаи затларның хәрәкәтләренә (хәрәкәтсезлегенә) шикаять бирү тәртибе;

мәҗбүри таләпләр кертелгән норматив-хокукый актлар турында мәгълүмат алу.

Телдән консультацияләр шулай ук халык җыеннарында һәм конференцияләрдә бирелергә мөмкин.

3.10. Язмача консультация бирү контрольдә тотылучы заттан әлеге Нигезләмәнең 3.9 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча язмача сорау алынган очракта гамәлгә ашырыла.

Язмача мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре турындагы җавапны контрольдә тотылучы зат 02.05.2006 елгы 59-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында»гы Федераль закон белән билгеләнгән вакытларда алырга һем бурычлы. Контрольдә тотылучы затлардан һәм аларның вәкилләреннән ике яки аннан да күбрәк бер төрдәге мөрәҗәгать килгән очракта, Сокуры авыл җирлегенең рәсми сайтында Башкарма комитет җитәкчесе яки вазыйфаи зат кул куйган язмача аңлатма урнаштырыла.

Консультация биргәндә вазыйфаи зат Россия Федерациясе законнары нигезендә чикләнгән мәгълүматның конфиденциальлеген сакларга бурычлы.

Консультация барышында конкрет контроль чарасына, вазыйфаи затларның карарларына яки хәрәкәтләренә бәя бирүче мәгълүмат, шулай ук экспертиза һәм сынау нәтиҗәләре бирелә алмый. Консультация вакытында алынган мәгълүмат Контроль органы тарафыннан контрольдә тотылучы затка мәҗбүри таләпләрне саклау мәсьәләләре буенча бәя биргәндә кулланыла алмый.

3.11. Профилактик визит вазыйфаи зат тарафыннан контрольдә тотылучы затның эшчәнлек алып бару урынында яисә видеоконференция, «Инспектор» мобиль кушымтасы аша профилактик әңгәмә формасында үткәрелә.

Профилактик визит барышында контрольдә тотылучы затка аның эшчәнлегенә яисә карамагындагы объектларга куелган мәҗбүри таләпләр, аларның куркыныч категорияләренә туры килүе, куркыныч дәрәҗәсен төшерү ысуллары, шулай ук контроль чараларының төрләре һәм ешлыгы турында мәгълүмат бирелә. Инспектор, үз чиратында, контроль объекты белән таныша, объектны куркыныч категориясенә кертү өчен кирәкле мәгълүматлар җыя һәм контрольдә тотылучы затның мәҗбүри таләпләрне үтәү дәрәҗәсенә бәя бирә.

Профилактик визит Контроль органы башлангычы белән (мәҗбүри профилактик визит) 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 52.1 матдәсендә билгеләнгән тәртиптә, яисә контрольдә тотылучы затның башлангычы белән әлеге законның 52.2 матдәсендә билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

4 нче бүлек. Контроль чараларын һәм контроль хәрәкәтләрен гамәлгә ашыру

4.1. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда Контроль органы түбәндәге төр планнан тыш контроль чараларын һәм алар кысаларында контроль хәрәкәтләрен үткәрә ала:

1. Инспекция визиты (тикшерү, сораштыру, мәҗбүри таләпләр буенча контрольдә тотылучы затның эшчәнлек урынында булырга тиешле документларны таләп итү, язмача аңлатмалар алу, инструменталь тикшерү аша). Бер эшчәнлек урынында яки бер объектта (территориядә) инспекция визиты уздыру вакыты бер эш көненнән артмаска тиеш;

2. Рейд тикшерүе (тикшерү, сораштыру, язмача аңлатмалар алу, документларны таләп итү, инструменталь тикшерү, сынау, экспертиза аша). Рейд тикшерүен үткәрү вакыты ун эш көненнән артмаска тиеш. Рейд барышында бер контрольдә тотылучы зат белән хезмәттәшлек итү вакыты бер эш көненнән артмаска тиеш;

документаль тикшерү (язмача аңлатмалар алу, документларны таләп итү,

экспертиза аша). Документаль тикшерү үткәрү вакыты ун эш көненнән артмаска тиеш;

күчмә тикшерү (тикшерү, сораштыру, язмача аңлатмалар алу, документларны таләп итү, инструменталь тикшерү, сынау, экспертиза аша). Күчмә тикшерү үткәрү вакыты 10 эш көненнән артмаска тиеш. Кече эшкуарлыкның бер субъектына карата күчмә тикшерү барышында хезмәттәшлек итүнең гомуми вакыты кече предприятие өчен — 50 сәгатьтән, микропредприятие өчен 15 сәгатьтән артмаска тиеш. Берничә Россия Федерациясе субъекты территориясендә эшчәнлек алып баручы контрольдә тотылучы затка карата күчмә тикшерү вакыты һәр филиал, вәкиллек яки аерым структур бүлекчә өчен аерым билгеләнә;

мәҗбүри таләпләрне саклауны күзәтү (төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль объектлары турындагы мәгълүматларны җыю һәм анализлау аша, шул исәптән ведомствоара мәгълүмат алмашу барышында алынган, контрольдә тотылучы затлар тарафыннан бирелгән, дәүләт һәм муниципаль системалардагы, «Интернет» челтәрендәге, башка ачык чыганаклардагы мәгълүматларны, шулай ук фото-, кинотөшерү һәм видеоязма функцияләренә ия булган автоматик техник чаралар ярдәмендә алынган мәгълүматларны кулланып);

күчмә тикшереп чыгу (тикшерү, инструменталь тикшерү (видеоязма кулланып), сынау, экспертиза, үрнәкләр алу аша).

4.2. Мәҗбүри таләпләрне саклауны күзәтү һәм күчмә тикшереп чыгу Контроль органы тарафыннан контрольдә тотылучы затлар белән бәйләнешкә кермичә планнан тыш чаралар формасында үткәрелә.

4.3. Контрольдә тотылучы затлар белән бәйләнештә үткәрелә торган контроль чаралары 31.07.2020 елгы 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 матдәсе 1 өлешендә күздә тотылган нигезләр буенча гамәлгә ашырыла.

4.4. Планнан тыш контроль чарасын үткәрү турында карар кабул иткәндә һәм аның төрен сайлаганда, зыян китерү куркынычына бәя бирү максатыннан, Контроль органы мәҗбүри таләпләрне бозуның куркыныч индикаторларын эшләп чыгара.

Мәҗбүри таләпләрне бозуның куркыныч индикаторы — ул контроль объекты параметрларының туры килүе яки алардан тайпылуы. Бу параметрлар үзләре генә мәҗбүри таләпләрне бозу булып саналмый, ләкин алар югары дәрәҗәдәге ихтималлык белән мондый бозуларның барлыгын һәм канун белән саклanучы кыйммәтләргә зыян килү куркынычын күрсәтә.

Муниципаль контроль кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозуның куркыныч индикаторлары исемлеге әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта белән билгеләнгән.

4.5. Контрольдә тотылучы зат белән бәйләнештә үткәрелә торган контроль чаралары Контроль органының контроль чарасын үткәрү турындагы боерыгы (распоряжение) рәвешендә чыгарылган карар нигезендә башкарыла.

4.6. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру вакытында Контроль органы ведомствоара мәгълүмат алмашу кысаларында (шул исәптән электрон рәвештә) башка органнардан яисә әлеге органнарга караган оешмалардан документларны һәм (яки) мәгълүматларны, әгәр алар әлеге органнар яки оешмалар карамагында булса, түләүсез нигездә ала.

Әлеге документларның һәм (яки) мәгълүматларның исемлеге, аларны тәкъдим итү тәртибе һәм сроклары түбәндәгеләр белән билгеләнгән:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы распоряжениесе белән расланган исемлек (дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә ведомствоара мәгълүмат алмашу кысаларында башка дәүләт органнарынан, җирле үзидарә органнарынан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына караган оешмалардан сорала торган һәм алына торган документлар һәм (яки) мәгълүматлар исемлеге);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 6 мартындагы 338 номерлы «Дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында ведомствоара мәгълүмат алмашу турында»гы постановлениесе белән расланган Кагыйдәләр (дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләрен, муниципаль контроль төрләрен оештыру һәм гамәлгә ашыру вакытында контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан башка органнардан яисә әлеге органнарга караган оешмалардан ведомствоара мәгълүмат алмашу кысаларында алына торган документларны һәм (яки) мәгълүматларны тәкъдим итү кагыйдәләре).

4.7. Контрольдә тотылучы затның урнашкан (эшчәнлек юрыткан) урынында булмавы, яисә аның фактик рәвештә эшчәнлек алып бармавы, яисә контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрүне яки тәмамлауны мөмкин булмаслык иткән башка хәрәкәтләре (хәрәкәтсезлеге) сәбәпле контроль чарасын үткәрү мөмкин булмаса, инспектор контроль чарасын үткәрү мөмкин булмавы турында акт төзи.

Бу Акта контроль чарасының үткәрелмәү сәбәпләре күрсәтелә һәм инспектор әлеге Федераль законның 21 нче матдәсе 4 нче һәм 5 нче өлешләрендә билгеләнгән тәртиптә контрольдә тотылучы затка бу хакта хәбәр итә. Бу очракта инспектор контроль чарасы тәмамланганчыга кадәр теләсә кайсы вакытта әлеге чара кысаларында контроль хәрәкәтләрен башкарырга хокуклы.

4.8. Контроль чараларын үткәрүнең барлык очракларында да вазыйфаи затлар һәм контроль хәрәкәтләренә җәлеп ителгән затлар мәҗбүри таләпләрне саклау (бозу) исбатламаларын теркәү өчен фотога төшерү, аудио- һәм видеоязма, геодезик һәм картометрик үлчәүләрне куллана ала.

Контроль чаралары барышында фотога төшерү, аудио- һәм видеоязма яисә исбатламаларны теркәүнең башка ысулларын куллану кирәклеге

турындагы карарны Контроль органының вазыйфаи заты мөстәкыйль рәвештә кабул итә.

Мәҗбүри таләпләрне бозу исбатламаларын фото- яки видеофиксацияләү күчмә тикшерү (выездная проверка) һәм күчмә тикшереп чыгу (выездное обследование) вакытында мәҗбүри рәвештә башкарыла.

Исбатламаларны теркәү өчен карамактагы теләсә нинди техник чаралар кулланылырга мөмкин. Фотога төшерү, аудио- һәм видеоязма үткәрү турында контрольдә тотылучы затка мәҗбүри рәвештә хәбәр ителә.

Мәҗбүри таләпләрне бозуны фотога төшерү аша теркәү кеме белән дә ике төшерүдән (снимкадан) ким булмаска тиеш. Төшерү нокталары һәм юнәлешләре контроль чарасы үткәрелә торган объект схемасында билгеләнә. Фотога төшерү һәм видеоязма җитәрлек яктылык булган шартларда үткәрелергә тиеш.

Фотога төшерү, аудио- һәм видеоязма, геодезик һәм картометрик үлчәүләр үткәрү, шулай ук бу максатлар өчен кулланылган техник чаралар турындагы мәгълүмат контроль чарасы нәтиҗәләре буенча төзелә торган акта чагылыш таба. Фотога төшерү, аудио- һәм видеоязма нәтиҗәләре контроль (күзәтчелек) чарасы актының кушымтасы булып тора.

Мәҗбүри таләпләрне бозу исбатламаларын теркәү өчен фотога төшерү һәм видеоязма куллану Россия Федерациясенең дәүләт серен саклау турындагы законнары таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Контроль чаралары барышында инструменталь тикшерүләр Контроль органының вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан башкарыла торган геодезик үлчәүләр (билгеләүләр) һәм (яки) картографик үлчәүләр үткәрү аша гамәлгә ашырыла.

4.9. Контроль чарасы нәтиҗәләренә түбәндәгеләр керә: контрольдә тотылучы затның мәҗбүри таләпләрне үтәвенә бәя бирү, мәҗбүри таләпләрне бозуны кисәтү һәм (яки) туктату өчен шартлар тудыру, бозылган хәлне торгызу, җаваплылыкка тарту мәсьәләсен карау өчен вәкаләтле органнарга яки вазыйфаи затларга мәгълүмат җибәрү һәм (яки) Контроль органы тарафыннан 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 нчы матдәсе 2 нче өлешендә күздә тотылган чараларны куллану.

4.10. Контрольдә тотылучы зат белән бәйләнештә үткәрелә торган контроль чарасы тәмамлангач, контроль чарасы акты төзелә. Әгәр мондый чара нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланса, акта нәкъ менә нинди таләп бозылуы, аның нинди норматив-хокукый акт һәм аның структур берәмлеге белән билгеләнүе күрсәтелә. Күрсетелгән бозу контроль чарасы тәмамланганчы бетерелгән очракта, акта аны бетерү факты теркәлә. Мәҗбүри таләпләрне бозу исбатламалары булган документлар һәм башка материаллар актка теркәлергә тиеш. Контроль чарасы барышында тутырылган тикшерү битләре (проверочные листы) актка кушымта итеп бирелә.

4.11. Актны рәсмиләштерү контроль (күзәтчелек) чарасы үткәрелгән урында, чара тәмамланган көнне башкарыла. Әгәр әлеге Федераль закон белән билгеләнгән сәбәпләр аркасында актны үткәрү урынында төзү мөмкин булмаса, ул чара тәмамланган көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча рәсмиләштерелергә тиеш (әгәр Федераль закон яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан башка тәртип билгеләнмәгән булса). Контроль чаралары турындагы мәгълүмат Контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрына кертелә.

4.11. Актны рәсмиләштерү контроль (күзәтчелек) чарасы үткәрелгән урында, чара тәмамланган көнне башкарыла. Әгәр әлеге Федераль закон белән билгеләнгән сәбәпләр аркасында актны үткәрү урынында төзү мөмкин булмаса, ул чара тәмамланган көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча рәсмиләштерелергә тиеш (әгәр Федераль закон яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан башка тәртип билгеләнмәгән булса). Контроль чаралары турындагы мәгълүмат Контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрына кертелә.

Эшкуарлык эшчәнлеге алып баручы булмаган һәм контрольдә тотылучы зат булып саналган гражданга вазыйфаи затларның хәрәкәтләре һәм кабул ителгән карарлар турында мәгълүмат кәгазьдәге документларны юллау аша җиткерелә. Бу түбәндәге очракларда башкарыла:

граждан Контроль органына документларны кезәгьдә алу кирәклеге турында белдерү җибәрсә;

Контроль органында контрольдә тотылучы затның электрон почтасы турында мәгълүмат булмаса;

документларны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша электрон рәвештә җибәрү мөмкинлеге булмаса (затның бердәм идентификацияләү һәм аутентификацияләү системасында исәп язмасы булмаган яисә теркәү процедурасы тәмамланмаган очракта).

Әлеге граждан Контроль органына документларны кәгазьдәге чыганакта җибәрергә хокуклы.

4.13. Контроль чарасы барышында мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланмаса, бу турыдагы мәгълүмат Контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрына кертелә. Вазыйфаи зат мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча тәкъдимнәр бирергә, канун белән саклануучы кыйммәтләргә зыян китерү куркынычларын профилактикалауга юнәлтелгән башка чаралар үткәрергә хокуклы.

4.14. Контроль чарасы барышында контрольдә тотылучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләр бозылуы ачыкланган очракта, Контроль органы (вазыйфаи зат) үз вәкаләтләре кысаларында түбәндәгеләрне эшләргә бурычлы:

контроль чарасы акты рәсмиләштерелгәннән соң, контрольдә тотылучы затка ачыкланган бозуларны бетерү турында предписание бирергә. Анда

бозуларны бетерү өчен нигезле (акыллы) сроклар, шулай ук федераль закон белән күздә тотылган башка чаралар күрсәтелә;

контроль чарасы барышында контроль объектына ия булган һәм (яки) аның белән файдаланучы гражданинның, оешманың эшчәнлеге канун белән сакланучы кыйммәтләргә турыдан-туры зыян (зыян салу) китерү куркынычы янаганы яисә мондый зыян китерелгәнлеге ачыкланса, кичекмәстән Россия Федерациясе законнарында күздә тотылган чараларны күрергә: зыян китерүгә юл куймаска яки аны туктатырга, шулай ук гражданнарга, оешмаларга куркыныч янавы һәм аны булдырмау ысуллары турындагы мәгълүматны теләсә кайсы үтемле ысул белән җиткерергә;

контроль чарасы барышында җинаять яки административ хокук бозу билгеләре ачыкланганда, үз компетенциясенә ярашлы рәвештә тиешле мәгълүматны дәүләт органына җибәрергә яки гаепле затларны закон белән билгеләнгән җаваплылыкка тарту чараларын күрергә;

ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерүне контрольдә тоту, аларны кисәтү буенча чаралар күрергә; предписание билгеләнгән срокларда үтәлмәгән очракта, аны үтәүне тәэмин итү чараларын күрергә, шул исәптән, әгәр закон белән күздә тотылган булса, предписаниены мәҗбүри рәвештә үтәтү турында судка мөрәҗәгать итәргә;

мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча тәкъдимнәр бирү, канун белән сакланучы кыйммәтләргә зыян китерү куркынычларын профилактикалауга юнәлтелгән башка чаралар үткәрү мәсьәләсен карарга.

4.15. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда контрольгә вәкаләтле вазыйфаи зат билгеләнгән тәртиптә федераль башкарма хакимият органнары һәм аларның территориаль органнары, Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, хокук саклау органнары, оешмалар һәм гражданнар белән үзара хезмәттәшлек итә.

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль кысаларында контроль чарасы үткәргәндә закон таләпләрен бозу ачыкланса һәм аның өчен Россия Федерациясе законнарында административ яки башка төр җаваплылык күздә тотылган булса, контроль чарасы актында ачыкланган бозу билгеләре турында мәгълүмат күрсәтелә. Контрольгә вәкаләтле вазыйфаи зат әлеге актның күчермәсен тиешле җаваплылыкка тарту вәкаләте булган хакимият органына юллый.

## 5 нче бүлек. Администрация карарларына, вазыйфаи затларның хәрәкәтләренә (хәрәкәтсезлегенә) шикаять бирү

5.1. Контроль органының карарларына, вазыйфаи затларның хәрәкәтләренә (хәрәкәтсезлегенә) 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы «Российская Федерациядә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»гы Федераль законның 9 нчы бүлегендә билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

5.2. Төзекләндерү өлкәсендә контроль гамәлгә ашырылганда хокуклары

һәм законлы мәнфәгатьләре, аларның фикеренчә, турыдан-туры бозылган контрольдә тотылучы затлар түбәндәгеләр буенча судка кадәр шикаять бирергә хокуклы:

контроль чараларын һәм мәҗбүри профилактик визитларны үткәрү турындагы карарлар;

контроль чаралары һәм мәҗбүри профилактик визитлар актлары, ачыкланган бозуларны бетерү турындагы предписаниеләр;

контроль чаралары һәм мәҗбүри профилактик визитлар кысаларында вазыйфаи затларның хәрәкәтләре (хәрәкәтсезлеге);

контроль объектларын тиешле куркыныч категориясенә кертү турындагы карарлар;

контрольдә тотылучы затларның гаризалары буенча мәҗбүри профилактик визитлар үткәрүдән баш тарту турындагы карарлар;

248-ФЗ номерлы Федераль закон белән күздә тотылган, профилактика һәм (яки) контроль чаралары нәтиҗәләре буенча контрольдә тотылучы затларга яисә контроль объектларына карата Контроль органы тарафыннан кабыл ителгән башка карарлар.

5.3. Шикаять контрольдә тотылучы зат тарафыннан Контроль органына электрон рәвештә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы һәм (яки) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталы аша бирелә.

Дәүләт серен яисә закон белән саклануочы башка серне тәшкил итүче мәгълүматлар һәм документлар булган шикаять, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын һәм региональ порталын кулламыйча, Россия Федерациясенең дәүләт сере һәм закон белән саклануочы башка сер турындагы законнары таләпләрен исәпкә алып бирелә. Мондый шикаятьне контрольдә тотылучы зат, шикаятьтә (документларда) дәүләт серен яисә закон белән саклануочы башка серне тәшкил итүче мәгълүматлар булуы турында Җитәкчене алдан хәбәрдар итеп, шәхси кабул итү вакытында тапшыра..

5.4. 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 40 нчы матдәсе 2 нче өлешенең 4 нче пункты нигезендә, Контроль органы карарына, вазыйфаи затларның хәрәкәтләренә (хәрәкәтсезлегенә) карата шикаять авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан карала.

5.5. Контроль органы карарына, вазыйфаи затларның хәрәкәтләренә (хәрәкәтсезлегенә) шикаять контрольдә тотылучы зат үз хокуклары бозылуын белгән яисә белергә тиеш булган көннән башлап 30 календарь көне эчендә бирелә ала.

Контроль органының предписаниесенә шикаять контрольдә тотылучы зат тарафыннан предписание алынган мизгелдән башлап 10 эш көне эчендә бирелә ала.

Шикаять бирү срогы урынлы сәбәпләр аркасында үткәреп җибәрелгән очракта, шикаять бирүче затның үтенече (ходатайство) буенча бу срок Контроль органы (вазыйфаи зат) тарафыннан торгызылырга мөмкин.

Шикаять биргән зат, шикаять буенча карар кабул ителгәнче, аны кире

алырга хокуклы. Бу очракта шул ук нигезләр буенча кабат шикаять юллау рөхсәт ителми.

5.6. Контроль органы карарына, аның вазыйфаи затларының хәрәкәтләренә (хәрәкәтсезлегенә) шикаять, судка кадәр шикаять бирү астысистемасында теркәлгән көннән башлап унбиш эш көне эчендә каралырга тиеш.

5.7. Контрольдә тотылучы затның контроль объектларын тиешле куркыныч категориясенә кертү турындагы карарга шикаяте биш эш көненнән дә артмаган срокта карала.

## 6 нчы бүлек. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольнең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан кыйммәтләре

6 нчы бүлек. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольнең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан кыйммәтләре

6.1. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген һәм эффективлыгын бәяләү 248-ФЗ номерлы Федераль законның 30 нчы матдәсе нигезендә башкарыла.

6.2. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль өчен контрольнең түбәндәге төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан кыйммәтләре билгеләнгән:

Ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозулар арасыннан бетерелгән бозулар өлеше — 70%.

Контроль чараларын үткәргәндә Контроль органының һәм (яки) аның вазыйфаи затының хәрәкәтләренә (хәрәкәтсезлегенә) карата нигезле шикаятьләр өлеше — 0%.

Контроль чараларының гамәлдән чыгарылган нәтиҗәләре өлеше — 0%.

Контроль органы тарафыннан чыгарылган административ хокук бозулар турындагы карарларның гомуми саныннан суд тәртибендә гамәлдән чыгарылганнарының өлеше (Россия Федерациясе Административ хокук бозулар турындагы кодексының 2.7 һәм 2.9 матдәләре нигезендә гамәлдән чыгарылган карарлардан тыш) — 0%.

6.3. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль өчен түбәндәге индикатив күрсәткечләр билгеләнгән:

хисап чорында үткәрелгән планнан тыш контроль чаралары саны;

хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозуның куркыныч индикаторлары белән расланган параметрларга туры килүне яки алардан тайпылуны ачыклау нигезендә үткәрелгән планнан тыш контроль чаралары саны;

хисап чорында үткәрелгән бәйләнешле (взаимодействие) контроль чараларының гомуми саны;

хисап чорында үткәрелгән һәр контроль чарасы төре буенча бәйләнешле контроль чаралары саны;

хисап чорында дистанцион хезмәттәшлек чараларын кулланып үткәрелгән контроль чаралары саны;

хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитлар саны;

хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында белдерелгән кисәтүләр саны;

хисап чорында нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган контроль чаралары саны;

хисап чорында йомгаклары буенча административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль чаралары саны;

хисап чорында контроль чаралары нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;

хисап чорында контроль чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

хисап чорында прокуратура органнарына җибәрелгән һәм алар тарафыннан килештерүдән баш тартылган контроль чараларын үткәрү турындагы гаризалар саны;

хисап чоры ахырына исәпкә алынган контроль объектларының гомуми саны;

хисап чоры ахырына куркыныч категорияләренә кертелгән, исәпкә алынган контроль объектларының һәр куркыныч категориясе буенча саны;

хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә тотылучы затлар саны;

хисап чорында карата контроль чаралары үткәрелгән, исәпкә алынган контрольдә тотылучы затлар саны;

хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан судка кадәр тәртиптә бирелгән шикаятьләрнең гомуми саны;

хисап чорында Администрация тарафыннан карау срогы бозылган шикаятьләр саны;

хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан судка кадәр тәртиптә бирелгән, карау нәтиҗәләре буенча Контроль органы карарын тулысынча яисә өлешчә гамәлдән чыгару яки Контроль органы вазыйфаи затларының хәрәкәтләрен (хәрәкәтсезлеген) дөрес түгел дип тану турында карар кабул ителгән шикаятьләр саны;

хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан суд тәртибендә Контроль органы вазыйфаи затларының карарларына, хәрәкәтләренә (хәрәкәтсезлегенә) шикаять белдереп җибәрелгән дәгъва гаризалары саны;

хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан суд тәртибендә Контроль органы вазыйфаи затларының карарларына, хәрәкәтләренә (хәрәкәтсезлегенә) шикаять белдереп җибәрелгән һәм алар буенча белдерелгән таләпләрне канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән дәгъва гаризалары саны.

хисап чорында муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру таләпләрен тупас бозып үткәрелгән һәм нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган яисә гамәлдән чыгарылган контроль чаралары саны.

***Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы Нигезләмәгә 1 нче кушымта***

**КОНТРОЛЬ ОБЪЕКТЛАРЫН КУРКЫНЫЧ КАТЕГОРИЯЛӘРЕНӘ КЕРТҮ КРИТЕРИЙЛАРЫ**

| **№** | **Контроль объектларын куркыныч категорияләренә кертү критерийлары** | **Куркыныч категорияләре классификациясе** |
|---|---|---|
| 1 | — гамәлдәге норматив-хокукый актлар нигезендә бирелгән рөхсәткә ярашлы рәвештә җир эшләре башкару;<br><br>— кышкы чорда муниципаль берәмлек территориясен җыештыру, шул исәптән бина һәм корылма түбәләрен кардан, боздан һәм боз сөңгеләреннән чистарту чаралары. | Уртача куркыныч категориясе |
| 2 | — биналарның, корылмаларның фасадларын, шулай ук төзекләндерүнең башка элементларын һәм җәмәгать урыннарын карап тору. | Чамалы куркыныч категориясе |
| 3 | — башка куркыныч категорияләренә кертелмәгән контроль | Түбән куркыныч |

| | | |
|---|---|---|
| | объектлары. | категориясе |

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы Нигезләмәгә 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге Контроль органы тарафыннан төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда планнан тыш тикшерүләр үткәрү кирәклеген билгеләү өчен кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозуның куркыныч индикаторлары**

1. Сокуры авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне контрольдә тотылучы зат тарафыннан сакламау билгеләре турында гражданнардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, юридик затлардан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан Контроль органы адресына килгән мөрәҗәгатьләр (мәгълүматлар) санының, узган елның шундый ук чоры белән чагыштырганда, квартал эчендә 20 һәм аннан да күбрәк процентка артуы.

Сокуры авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне контрольдә тотылучы зат тарафыннан сакламау билгеләре турында гражданнардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, юридик затлардан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан Администрациягә 60 көн эчендә ике яки аннан да күбрәк мөрәҗәгать (мәгълүмат) килүе, әгәр әлеге мөрәҗәгатьләрнең (мәгълүматларның) беренчесе килгәнчегә кадәр бер ел эчендә контрольдә тотылучы затка шундый ук мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү белдерелгән булса.